**Гайфетдинов Хәнәфи**

# КАЛМЫК БАЗАРЫНДА

1911 нче елның язы иде Абый шәһәрдән кайтты да кунак каршыларга хәзерлек башлады. Без ул чакта авыл мәктәбе йортында тора идек. Абый мәктәп бинасындагы үзенең бүлмәсеннән артык әйберләрне чыгартты. Бүлмә эчендә фәкать карават, язу өстәле, китаплар белән тулы киштә генә калды.

Без Шәйхегали Туликов йортына барып, аның үзе йөри торган тарантасына ат җиктердек һәм шәһәрдән килә торган пароходны каршыларга пристаньга төшеп киттек. Мин ат тотучы булдым.

Пароход килде. Пассажирлар пристаньнан чыгып беткәч, Шәһит абый да тәбәнәк буйлы бер егетне җитәкләп чыкты. Алар янында Сәгыйть Рәмиев һәм тагын берничә кеше бар иде. Мин аларны таный идем. Сәгыйть Рәмиев таза гәүдәле, башына көрән төстә эшләпә киеп, иңенә ике зур төймә белән элдергән макинтош салган, кулына трость тоткан иде.

Кунаклар тарантаска урнашып беткәч, мин атны зур урамнан чаптырып, аларны өйгә алып кайттым. Соңыннан әлеге егетнең шагыйрь Габдулла Тукай булуын белдем.

Кунакларны өйгә алып кергәч, абый минем янга чыкты да:

– Син, Хәнәфи, атны хуҗасы йортына илтеп тапшыр. Иртәгә аннан ук рессор кузалак * җиктереп, Кендекле күлгә барырсың һәм кымыз алып кайтырсың,–

Рессор   кузалак – ике тәгәрмәчле сиртмәле арба.

диде... Шулай көн аша Габдулла Тукай өчен кымыз ташыдым. Ул аны бик кыстатып, яратмыйча гына эчә иде. Бездән киткәндә Тукай минем кулымны кысып:

– Рәхмәт, энем, кымыз ташып эчерткән өчен!– диде.

Шулай да кымызның шифасы тиде: шагыйрь тазарды, йөзендәге сарылык югалып, бит урталары тулып китте.

Мин ул чакта яшь идем. Шуңа зурлар арасына керми, аларның нәрсәләр сөйләшкәнен тыңламый идем.

Габдулла Тукай көне буе бүлмәдә ялгыз була, һаман укый һәм яза иде. Аның тик бер тапкыр абыйга бездә бер мәҗмуга булырлык шигырьләр яздым дигәнен генә ишеттем.

Шәһит абый аның бик күп шигырьләренә рәсемнәр ясады. Тукай аларны бик яратты...

Тукай бездә торган чакта, шәһәрдән көн дә диярлек кунаклар килә, үзләре дә абый белән көн өстенә генә шәһәргә барып кайталар иде.

Тукай Калмык базарында вакытта артистлар килеп, театрлар да куйгаладылар. Шул вакытта Камил Мотыйгый да килде. Аның концерты турында «Борһане тәрәкъкый»дә басылган отчетта «концертта Казан кунаклары да булды» дип яздылар.

Тукай бездә чакта абыйның дусы фотограф И. М. Бочкарев килде. Ул килгән көнне Шәһит абый Тукайның берничә шигырен җанландырып күрсәтте. Бу күренешләрне Бочкарев рәсемгә төшерде.

Шәһит абый Хаҗи булып, ә җиңгәм Нурбиби яшь кыз булып киенделәр. Идәнгә җәелгән табынга Шәйхегали бай биргән ат казылыгы, тутырган каз һәм бер табак кымыз куелды. Бу рәсем соңыннан русча һәм татарча язулы, төсле открытка итеп таратылды. Аңа Габдулла Тукайның «Бер шәехнең мөнаҗаты» шигыреннән беренче куплет язылган иде:

«И ходай! мәгълүм сиңа, тик яхшылыкта касдымыз.

Зикремездер: казы, кузый, яшь кенә кыз, каз, кымыз».

Абый белән җиңги шунда ук «Егет илә кыз», «Шайтанның муенына» һәм башка шигырьләрне театрлаштырдылар.

Бик күңелле булды ул утырыш!

Безнең абый 1907 нче елда Әстерханда чыккан «Туп» журналына ясаган рәсемнәре өчен бик нык эзәрлекләнүенә, хәтта жандармнар кулга алудан калмык далаларына качып кына котылуына карамастан, карикатуралар һәм рәсемнәр ясаудан тукталмады. Ул аларны Тукайга, «Ялт-йолт» журналына да җибәреп торды.

Тукай кайчак Идел буена барып яр башында да утыра иде. Аңа ияреп мин дә бара идем. Бу бик эссе, Һава бик бөркү көннәр башлангач булды.

Тау башыннан бөтен тирә-як уч төбендә кебек күренә. Алда, һавага җиләс өреп, киң һәм мәһабәт Идел ага. Аның икенче ягында – урманлык, аннан болынлык. Алар өстендә әледән-әле яшен шәүләсе чагыла...

Габдулла Тукай, Идел аръягына, судан үтүче пароходларга һәм көймәләргә, су коенучы балаларга карап, озак утыра торган иде. Кайчак ул моңланып авыз эченнән генә җырлап та ала.

Тукай безнең мәктәп өчен дә бер шигырь язып калдырды. Без аны дәресләр тәмамлангач, өйгә кайтырга җыенгач, аягүрә торып, төрек маршына охшаган бер көйгә җырлый идек.

***Сәгыйть Рәмиев белән (Вәлит Алиев истәлеге)***

Тукай Әстерханга килгәндә, Сәгыйть Рәмиев минем абыем Даут Мөхәммәдиевләрдә тора иде.

Даут абый көймәләр күтәрүче һәм конопатчы эшчеләр бригадиры булса да, бик прогрессив кеше иде. Ул Нариман Нариманов белән дә дус, аның белән йөрешә иде. Аның хатыны Әстерхан хатын-кызларыннан беренче булып сәхнәгә чыкты. Даут абый үзе дә спектакльләр, төрле җәмәгать чаралары оештыруга катнаша иде. Шуңа ул, Тукай килү хәбәрен ишетү белән, Сәгыйть Рәмиевкә Тукайны «Люкс» номерыннан үз өйләренә алырга тәкъдим итте. Соңыннан ул бөтен буш вакытын кунагы Тукайның Әстерханда булуын оештыруга багышлады. Тукайның авыру булуын күреп, Даут абый Сәгыйть Рәмиев белән бергәләп аны доктор Нариманов-ка алып бардылар.

Нариман Нариманов Тукайның авыруын карагач:

– Бер-ике сәнә мөкатдәм килү кирәк иде,– дигән.

*Бер-ике сәнә мөкатдәм – бер-ике ел элгәре.*

Шулай да аңа көч җыярга, кымыз эчеп карарга киңәш биргән.

Шул киңәш буенча Тукай Калмык базарында, укытучы Шәһит Гайфидә торып, кымыз эчте.

Доктор Нариманов һәр ел ромашка чәчәк ата башлаган көннәрдә «Ак чәчәк бәйрәме» оештырып, туберкулезга каршы көрәш кампаниясе үткәрә иде. Шуңа хәзерлек барган көннәрдә, Тукай белән танышкач, ул аңа бу чарага катнашырга тәкъдим итә һәм Тукай аны кабул итә.

Әле дә исемдә: «Ак чәчәк бәйрәме» уңае белән Губернатор бакчасында (хәзер Туганнар бакчасы) митинг булды. Анда Нариман Нариманов бәйрәмнең әһәмияте, туберкулезга каршы көрәшнең бөтен халык эше булуы турында сөйләде. Аннан ул татарның атаклы шагыйре Габдулла Тукайга сүз бирде. «Атаклы» сүзен ишеткәнгәме (ул үзен олылаганны һич тә яратмый иде), әллә-сөйләргә

хәзер булмагангамы, Тукай аптырап калды. Шулай да ул халыкны агарту, культурага якынайту, уку кирәклек турында сөйләде.

Туберкулезга каршы көрәш фондына җыелган акчага доктор Нариманов Петроградтан профессор чакырта һәм, туберкулез белән авыручыларны аңа күрсәтеп, аларны дәвалауны оештыра иде. Ул үзе ярлыларны акчасыз карый, кайбер бик мохтаҗларына аптекадан дару сатып алырга акча да бирә иде.

Нариманов һәр көн губернатор канцеляриясенә барырга тиеш була, аңа шәһәрдән чыгарга рөхсәт ителми. Шуңа карамастан ул, авыруны дәваларга бару сылтавы белән, тирә-як авылларга да чыга, анда беседалар үткәреп, халыкның аңын күтәрү буенча зур эш алып бара иде.

Тукай катнашкан Сәмәк авылындагы маевкага да ул, үзенең яхшы танышы, бакча хуҗасы Латыйп Умәровны дәваларга дигән сылтау белән, ялгыз фаэтонга утырып бара.

Тагын Тукайның Яңа Гаскәр авылына барганын хәтерлим. Анда баруны Даут Мөхәммәдев оештырды. Ул моторлы көймә сорап алды. Бу юлы мине «кушчы бала» – йомыш үтәүче итеп алдылар.

Язгы ташу вакыты иде. Көймә Аударма елгасыннан барды. Яңа Гаскәрдә «Ирагаҗы» зиратында булдык. Сәгыйть Рәмиев турыдан-туры  каберлеккә барып керде, аннан аңа каршы Мөҗавир килеп чыкты.  Сәгыйть аптырап калмады:

– Галимҗан  хәзрәт шәкертләрен  изге  аталарга Коръән укырга алып килдем,– диде.

Бу сүзләрдән мөҗавир үзе аптырап калды.

– Ай, алай булгач, мин кузы чалып китерим, сәвап булыр,– диде ул һәм ашыгып авылга китте.

Бу эше өчен Сәгыйтьне Тукай әрләп:

– Әй,  Сәгыйть, каберлеккә  кермик  дип әйттем бит!– диде.

Шулай да бу сәяхәт бик күңелле булды. Тукай да бик риза булып кайтты.

Галимҗан хәзрәт дигәч, тагын бер кызыклы хәл хәтеремдә. Тукай минем абый – Мәзһәр Моради-Алиев белән бергә укыган булган. Мәзһәр абый Казанда Галимҗан хәзрәт мәдрәсәсендә үлеп кала. Тукайны Әстерханда Мәзһәрләргә Габдерәхим Сәмәки алып барды. Киткәндә Мәзһәрнең анасы, аларны озата чыгып, Тукайга:

– Мә, балам Габдулла, Мәзһәр рухына укырсың, – дип, ун сум акча тоттырды.

– Әнкәй, мин сәдака алмыйм,– дип, Тукай акчаны кире кайтарды.

Габдерәхим Сәмәки (чын фамилиясе Әбүбәкерев) – Тукайның күптәнге танышы иде. Алар Уральскида Габдулла Тукай Камил Мотыйгый матбагасында эшләгәндә танышалар. Сәмәки Тукайның басылмаган күп эпиграммаларын белә иде.

Мин тагын Тияктә үткәрелгән әдәби ахшамда булдым. Зал шыгырым тулы иде. Кичәдә Габдулла Тукай халык әдәбияты турында сөйләде. Аннан соң артист Габдерәхим Адаков, Бари Әминев, Әҗдәр Моратов һәм башкалар Тукай шигырьләрен укыдылар. Җыелучылар Габдулла Тукайны бик олылап тәбрикләделәр.

Тукай Әстерханда вакытта җырчы Мәрьям Искәндә-рова концерты булды, ул Касыйм шәһәреннән, Петербургта консерватория тәмамлаган җырчы иде. Бу концертка Сәгыйть Рәмиев һәм Даут абыйлар Тукайны көчләп алып бардылар. Концерт «Аркадия» исемле җәйге бакчада булды (хәзер анда Карл Маркс исемендәге шәһәр культура һәм ял паркы).

*Мөҗавир – ziратта торучы, сакчы.*

Төскә-биткә чибәр, матур җырлаучы артистканы Әстерхан публикасы бик җылы каршылады. Байлар визит карточкалары, хәтта акча да салган чәчәк бәйләмнәрен сәхнәгә яудырдылар. Ләкин аларның җырчыны үз якларына аударырга маташулары бушка чыкты. Сәгыйть Рәмиев аның белән көрешеп, Габдулла Тукайның да концертта булуын әйтеп өлгергән иде. Җырчы Мәрьям концерттан соң Габдулла Тукай утырган өстәлгә барды. Мәрьямне як-яктан чакырсалар да, ул берсенә дә игътибар бирмәде. Бу хәл байлыклары белән кәперенүче, культурадан, шигърияттән, музыкадан хәбәре булмаган кешеләрдә зур ачу тудырды. Алар җырчының шагыйрьләр белән сөйләшергә теләгәнен аңламадылар. Киресенчә, ул кешеләр Мәрьям Искәндәрованы үз якларына аударучыларны кыйнатырга маташып карадылар һәм «Борһане тәрәккый» газетасын аларга яла ягу өчен файдаланып, анда карикатура урнаштыруга ирештеләр. Бу хәлгә доктор Наримановның бик ачуы килә һәм ул, редакциягә барып, мөхәррир Мостафа Лотфыйны бик нык тирги.

Тукай китәр алдыннан аның Шәрәфенә шәһәрдә, кышкы театрда, Зәйни Солтанов җитәкчелегендә зур кичә үткәрелде. Анда катнашучыларның Тукай белән бергә төшкән рәсеме әле дә күп кешеләрдә саклана. Бу кичәдә Әстерхан шәһәре кызларыннан беренче булып Сара ханым Байкина сәхнәгә чыкты.

Габдулла Тукайны Әстерханнан бик олылап озаттылар, Тукай Әстерханнан 1 класста, аерым каютада китте. Ул үзе дә килгәндәгедән күп үзгәргән иде: башына эшләпә, өстенә европача тегелгән яхшы костюм кигән, ак яка салып галстук бәйләгән, кымыздан соң шактый тазарган һәм матурайган иде.